СОВЕТ СВИЯЖСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ СВИЯЖСК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Тел/факс: (84371) 3-89-00, E-mail:Svg.Zel@tatar.ru, Сайт https://zelenodolsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«04» июне 2024 елның а. Свияжск (Зөя) № 157

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Свияжский авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Свияжское авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, Свияжский авыл җирлеге Советы **карар кабул итте:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Свияжск (Зөя) авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау;

гарантияләнгән җирләү хезмәтләре исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне Свияжский (Зөя) авыл җирлеге башкарма комитетына кабул иткән очракта:

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Свияжск (Зөя) авыл җирлеге бюджеты турында карарга үзгәрешләр кертү хакында Свияжск (Зөя) авыл җирлеге Советы Карары проектын әзерләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тапшырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск

муниципаль районы Зеленодольск авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында: Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Свияжск (Зөя) авылы, Успенская урамы, 11 йорт (поселение администрациясе), Успенская, 2 нче йорт (Буян кибете керү урынында).

4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

**Башлыгы җирлеге,**
**Совет рәисе** **М.Г. Ганеев**